**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

25.03.2024 ел № 5

2003 елның 6 октябреннән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июленнән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, 2024 елның 15 мартыннан Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгының "2023 елның 24 ноябреннән Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында»гы 3 санлы гражданнар җыеннары карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 7 санлы, 2023 елның 24 ноябреннән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында»гы 3/1 санлы карарлары нигезендә, 2024 елның 25 мартында булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:

"2023 елның 24 ноябреннән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2023 елның 24 ноябреннән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»гы 3/1 санлы гражданнар җыеннары карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1) Подгорный торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктта яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү челтәрләре төзү, проект төзү, материаллар, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Подгорный торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (материаллар, янгын гидрантлары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Подгорный торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек юлларын карап тоту, юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 378 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 148 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «риза» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 148 кеше тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда әйтелгәннәргә нигезләнеп, гражданнар җыены карар итте:

1. Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыенын узган һәм гражданнар җыены нәтиҗәләрен чынбарлыкка туры килә дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны тану:

"2023 елның 24 ноябреннән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

турында»гы 3 санлы, 2023 елның 24 ноябреннән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Подгорный торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында»гы 3/1 санлы гражданнар җыеннары карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә Сез ризамы:

«1) Подгорный торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм торак пунктта яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү челтәрләре төзү, проект төзү, материаллар, җиһазлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Подгорный торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (материаллар, янгын гидрантлары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Подгорный торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек юлларын карап тоту, юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)» - сорауларын кабул ителгән дип санарга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында, Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://yutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы ______________ З.М.Әһлиева
(имза)